# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында"
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 12 мартында
кабул ителде

**1 статья**

"Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында" 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 5 һәм 6 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Профессиональ дини белем бирү учреждениеләре (рухани белем бирү учреждениеләре) дини оешмалар сыйфатында теркәлергә тиеш һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукына дәүләт лицензиясе алалар. Профессиональ дини белем бирү учреждениеләре (рухани белем бирү учреждениеләре) лицензияләр нигезендә, федераль дәүләт мәгариф стандартлары таләпләренә таянып, белем бирү программаларын гамәлгә ашырырга һәм, дәүләт аккредитациясе алган очракта, тиешле белем дәрәҗәсе турында дәүләт үрнәгендәге документларны билгеләнгән тәртиптә бирергә хокуклы. Профессиональ дини белем бирү учреждениесенең (рухани белем бирү учреждениесенең) дәүләт статусы (белем бирү учреждениесенең үзе гамәлгә ашыра торган белем бирү программалары дәрәҗәсе һәм юнәлеше нигезендә билгеләнә торган тибы, төре һәм категориясе) аны дәүләт тарафыннан аккредитацияләгәндә билгеләнми.

6. Дәүләт лицензиясе булган профессиональ дини белем бирү учреждениеләренең көндезге бүлекләрендә укучы гражданнар Россия Федерациясе законнарында каралган ташламалардан файдаланалар.";

2) 7 статьяның 2 өлешендәге бишенче абзацын төшереп калдырырга;

3) 15 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Чит ил дини оешмасы вәкиллеген теркәү, ачу һәм ябу тәртибе Россия Федерациясе законнары нигезендә федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 31 марты
№ 12-ТРЗ